КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 март г.Казань № 223

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 53 нче; 2020 ел, 21 ноябрь, 1043 нче; 2021 ел, 20 июль, 615 нче; 2022 ел, 8 апрель, 333 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә, 7 пунктның 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12) хезмәт эшчәнлеге турында кәгазь чыганакта мәгълүматлар (хезмәт кенәгәсе – барлык битләрнең эш бирүче тарафыннан расланган күчермәсе) һәм (яки) тиешле рәвештә расланган кәгазь чыганакта яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин